**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**«07» июнь, 2023 ел** **№ 298**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясының 13 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәләрен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Биектау муниципаль районы Советының 2022 елның 24 июнендәге 179 номерлы карары белән расланган Генераль планына кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына Федераль дәүләт территориаль планлаштыру мәгълүмат системасының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлегенең Генераль планын урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов

Дачный авыл җирлеге Генераль планына материаллар белән https://fgis-tp.ru сайтында танышырга була.